КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август

г.Казань

№ 720

Юридик затларга каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле юридик затларның чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Юридик затларга каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 720 нче карары
белән расланды

Юридик затларга каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм юридик затларга каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны кайтаруга (алга таба – субсидия) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидия каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениесе булмаган юридик затка бирелә.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бирелә, аңа кадәр, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, бюджет акчаларын алучыга, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең лимитлары билгеләнгән тәртиптә бирелгән.

4. Субсидия алу өчен юридик затларны сайлап алу критерийлары булып торалар:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең түбәндәге төрләрен гамәлгә ашыру: кадастр, топография-геодезия, инженерлык эзләнүләр;

каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкару.

5. Түләүләргә субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү эшләрен башкаручы оешма хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләүгә чыгымнар һәм матди бүләкләү;

элемтә хезмәтләрен тәэмин итүгә чыгымнар;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү һәм биналарны арендага бирү чыгымнары;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү;

каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү эшләрен башкарганда программалы һәм мәгълүмати тәэминатка чыгымнар;

аэрофототөшерү эшләрен башкаруга киткән чыгымнар.

6. Субсидия субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килә торган юридик затка бирелә:

субсидия алучының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнелергә тиешле бурычлары булмаска тиеш;

субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар буенча бирелгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында срогы чыккан бүтән бурычлары юкка чыгарга тиеш;

субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган Россия юридик заты түгел;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы түгел;

7. Субсидия алу өчен юридик зат Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле формада төзелгән каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләрне башкаруга исәп-хисапларны теркәп һәм чыгымнарны нигезләп субсидияләр бирүгә заявка (алга таба - заявка);

каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча фактта башкарылган чыгымнарны, аларның күләмен (счет, счет-фактуралар, товар-транспорт накладнойлары, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләрне кабул итү актлары);

юридик затның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычның булмавын раслый торган документлар;

юридик затның үзгәртеп кору, бетерү яки банкротлык процессында булмавын раслаучы документлар;

юридик зат әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый дип раслый торган документлар.

Юридик зат үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик зат буларак юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның күчермәсе яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрын язу битенең күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә үтәлергә тиешле йөкләмәләрнең үтәлмәгәнлеген раслаучы документлар.

Юридик зат әлеге пунктның тугызынчы – унберенче абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык кушып бирелгән документлар белән гаризаларны алар кергән көннән бер көн эчендә кабул итә һәм терки.

Министрлык гаризаны теркәгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 20 көнлек срокта карый һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык формасында карар кабул итә.

9. Субсидия бирүдән баш тартуга нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы икенче - алтынчы абзацларында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

юридик зат тәкъдим иткән документларның әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

юридик зат тарафыннан бирелгән гаризада һәм әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

10. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәр тиешле карар кабул ителгән көннән соң биш эш көне эчендә Министрлык тарафыннан язма рәвештә юридик затка җибәрелә.

11. Субсидия бирү Министрлык һәм аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән субсидия алучы арасында субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешү, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган формага туры китереп, эш көннәрендә исәпләп, җиде көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидияләр күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләренең әһәмияте (калдык ресурс үлчәме буенча эшләр башкарылган каты коммуналь калдыклар полигоннары саны), каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар төрләре, субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү тәртибе, формасы һәм сроклары, Министрлык тарафыннан субсидия алучының Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруга ризалыгы карала, устав (җыелма) капиталларында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында аларның устав (җыелма) капиталларында шартлар, субсидияләр бирү максатларыннан һәм тәртибен, субсидия алучының әлеге тәртип шартларын һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләрне үтәүне тикшерүне дәүләт финанс контроле органнары

тарафыннан тикшерүләрне, шулай ук субсидия бирү максатларын һәм тәртибен, субсидия алучының әлеге тәртипне һәм, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кире кайтару тәртибе һәм сроклары күздә тотыла.

12. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү эшләрен башкаручы оешма хезмәткәрләрен фактта хезмәт өчен түләүгә тотылган һәм документаль расланган чыгымнар һәм матди бүләкләү;

$З_2$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле элемтә хезмәтләрен тәэмин итүгә фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар;

$З_3$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә һәм биналарны арендага бирүгә фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар;

$З_4$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр өчен фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар;

$З_5$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләрне башкарганда программалы һәм мәгълүмати тәэминатка фактта тотылган һәм документлар белән расланган чыгымнары;

$З_6$ – каты коммуналь калдыклар полигоннарының калдык ресурсын үлчәү һәм исәпләү буенча эшләр башкаруга бәйле аэрофототөшерү эшләрен башкаруга фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар.

13. Министрлык, субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә, субсидияне субсидия алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

14. Субсидия алучы субсидия акчаларын керү һәм тоту буенча аерым бухгалтер исбен алып бара.

15. Субсидия, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру;

билгеләнгән вакытта субсидиядән файдалану турында хисап тапшырмау;

Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тикшерүләре фактлары буенча ачыкланган субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны бозу очраклары ачыклану;

акчаларны куллану әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга туры килмәү.

16. Субсидияләр алучылар тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срогы бозылганд, Министрлык, субсидияләрне кире кайтару срогы чыккан көннән алып җиде көн эчендә әлеге акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

17. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерәләр.

18. Субсидияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын Министрлык Россия Федерациясе законнары нигезендә контрольдә тота.